СОВЕТ ЦИПЬИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧЕПЬЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ
17.07.2024

КАРАР
№ 124

**Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чепья авыл җирлеге башлыгының, Чепья авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең хезмәтенә түләү тәртибе турында»гы 2018 елның 25 декабрендәге 138 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 30.04.2024 290 нчы номерлы карары,«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең контроль-хисап палатасы рәисенә, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәре, айлык һәм башка өстәмә түләүләр һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе күләмнәре турында» Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2018 елның 28 апрелендәге 127 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Советының 04.06.2024 252 нче номерлы карары (2022 елның 13 октябрендәге 144 номерлы үзгәрешләре белән)» һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге Уставы нигезендә Балтач муниципаль районының  Чепья авыл җирлеге Советы карар итте:

1.«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге башлыгының, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең (алга таба - Карар) хезмәтенә түләү тәртибе турында» 2018 елның 25 декабрендәге 138 нчы номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктындагы 2 пунктчасында «12688» санын «13323» санына алмаштырырга;

1.2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге башлыгы, Чепья авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең хезмәтенә түләү Тәртибенең 1 пунктында «19039» санын «19991» санына алмаштырырга;

1.3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге башлыгы, Чепья авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең хезмәтенә түләү Тәртибенең 2 пунктында «10,36» санын «14,12» санына алмаштырырга;

1.4. Карарның 3 нче кушымтасының 6 пунктчасында «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алмаштырырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (www.baltasi.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземә калдырам.

4. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Чепья авыл җирлеге башлыгы А.Г. Нотфуллин